ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^{1}$ статьясына һәм «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының $10^{1}$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 15 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^{1}$ статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле $10^{11}$ һәм $10^{12}$ пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«$10^{11}$) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үстерү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителгән карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик затны билгеләү;

$10^{12}$) территорияне комплекслы үстерү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, җирле администрация башлыгы тарафыннан кабул ителә торган карарны гамәлгә ашыру максатларында төзелә торган Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 71 статьясындагы 5 өлешендә күрсәтелгән килешүне төзү очракларын, килешүнең эчтәлеген, аны төзү һәм гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;».

**2 статья**

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), «дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә» сүзләреннән соң «йә, торак төзелеше территориясен комплекслы үстерү хакындагы килешүдә каралган булса, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үстерү турындагы карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче юридик зат милкенә» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 26 февраль
№ 5-ТРЗ